Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кузайкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

11 ноябрь 2019 ел N 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Кузайкино авыл җирлегенең
Кузайкино авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә, 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылының Жданов, Заречная, Набережная, Полевая урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 23 ноябрендә, 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылының Совет урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 23 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында Хрусталев, Мәктәп урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Кузайкино авылы юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыены этапларын Кузайкино авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Кузайкино авылы, Совет урамы, 38 нче йорт.
6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
7. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кузайкино
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Шәйхетдинов